ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

02.04.2024 с. Коргуза 03

«Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылында гражданнар җыенының 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан РеспубликасыЮгары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылында гражданнар җыенының 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә».
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга :

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 01 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы?:

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү, мемориаль такталар урнаштыру, Патрикеево авылында һәйкәл территориясен тотып алу).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Патрикеево авыл клубы бинасында түбәндәге адрес буенча халык җыенын үткәрергә: Патрикеево авылы, Береговая урамы, 10 йорт 11.00 сәгатьтә.
4. Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д. В. Плохов